**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 16 » 05 2017 № 302

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 ноябрендәге 589 номерлы карары белән расланган Аксубай муниципаль районы «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Аксубай муниципаль районы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр керту турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 51 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 8 маендагы 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен, начальникларын) аттестацияләгәндә бертөрлелекне тәэмин итү максатларында,

**КАРАР БИРӘ:**

1.Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Аксубай муниципаль районы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 7 ноябрендәге 589 номерлы карары белән расланган Аксубай муниципаль районы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегендә 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аттестация комиссиясенең уңай карары кабул ителгән җитәкчеләр үз вазыйфасына билгеләнеп куела. Алар һәр 5 ел саен аттестацияләнә, һәр 3 ел саен база белем бирү оешмалары җитәкчеләре".

1.2.II “Аттестация үткәрү тәртибе” бүлегендә 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аттестация барышында хезмәткәрләр үзләре җитәкче вазифасы буенча хезмәт эшчәнлеген башкаруга бәйле тестлар буенча язма рәвештә квалификация

сынаулары уза. Аттестация тестлары Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе белән раслана.

Аттестация барышында база оешмалары җитәкчеләре җитәкче вазифасы буенча хезмәт эшчәнлеген башкару белән бәйле мәсьәләләр буенча компьютер тесты формасында квалификация сынаулары уза.

База оешмалары җитәкчеләре өчен компьютер тестлары Министрлык боерыгы буенча «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесендә үткәрелә.

Тест нәтиҗәләрен уңай исәпкә алу өчен кирәкле балларның минималь саны 100 баллдан 70 балл тәшкил итә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Житэкче А.Ф.Горбунов